ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан ш.

28.04.2022______________ №_63________________

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIII республика конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасында эчке һәм чит ил туризмын үстерү, яшьләрне инновацияле туристлык проектларын гамәлгә ашыруга җәлеп итү, Татарстан Республикасының өстенлекле туристлык үзәкләрен үстерү максатларында боерык бирәм:

1. 2022 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIII республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.
2. Туристлык индустриясен үстерү бүлегенә (А.А.Кайманова) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү эшен оештырырга.
3. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының «2021 елда «Чыганакларга сәяхәт» XII республика конкурсын үткәрү турында» 2021 елның 6 августындагы 131 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча рәис урынбасары Г.М.Сафинны җаваплы итеп билгеләргә.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2022 елның 28 апрелендәге 63 номерлы боерыгы белән расланды

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт»
XIII республика конкурсын үткәрү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2022 елда ХШІІ «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен, Конкурста катнашучыларга таләпләр, Конкурс проектларына карата таләпләр һәм аларны Конкурска бирү тәртибен, шулай ук Конкурсны үткәрү срокларын билгели.

1.2. Конкурсның максаты – яшьләрне Татарстан Республикасының туристлык үзәкләрен үстерү һәм алга этәрү буенча инновацияле туристлык проектларын гамәлгә ашыруга җәлеп итү, яшьләрдә туган якның туристлык ресурслары, аның мәдәни һәм экологик һәйкәлләре турында хәбәрдарлык дәрәҗәсен арттыру аша ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү.

1.3. Конкурсның төп бурычлары:

Татарстан Республикасы территориясенә туристларны җәлеп итүгә ярдәм итә торган туристлык, туган якны өйрәнү һәм мәдәни юнәлештәге проектларны булдыру һәм пропагандалау;

Татарстан Республикасында эчке һәм чит ил туристлыгын үстерү;

талантлы яшьләрне ачыклау һәм туристлык өлкәсенә җәлеп итү.

1.4. Конкурсны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) оештыра.

1.5. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасында каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Конкурста катнашу шартлары

2.1. Конкурста катнашу түләүсез, ирекле нигездә башкарыла.

2.2. Конкурста Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, эшли торган яшьләр, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан яшьләрнең иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнаша.

2.3. Конкурста катнашу өчен проектларны күрсәтү белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан да, претендентлар тарафыннан да гамәлгә ашырыла. Конкурста күмәк башкарылган эшләрнең катнаштырылуы рөхсәт ителә.

Конкурста катнашу бер яисә берничә номинациядә (теләккә карап) кабул ителә.

2.4. Конкурста 7 яшьтән 25 яшькә кадәрге физик затлар катнаша.

## 3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс бер этапка 2022 елның 19 сентябреннән 25 ноябренә кадәр үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турында мәгълүмат Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) (алга таба – Дәүләт комитеты сайты) конкурс проектларын кабул итә башлаганчы кимендә 15 календарь көне алдан урнаштырыла.

3.2. Конкурс проектларын Дәүләт комитетына тапшыру вакыты – 2022 елның 19 сентябреннән 20 октябренә кадәр.

Конкурс проектлары 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Максим Горький ур., 19 йорт (туризм индустриясен үстерү бүлеге) адресы буенча кулдан тапшырыла яки почта юлламасы белән җибәрелә. Почта аша җибәргәндә конкурс проекты шулай ук флеш-чыганакта да салына.

Конкурс проектының электрон версиясе Конкурсны оештыручының электрон адресына кабатлана – puteshestvie.kistokam@mail.ru

3.3. Шушы Нигезләмәнең 3.2 пунктчасында күрсәтелгән, үз вакытында тапшырылган, эчтәлеге һәм рәсмиләштерелеше шушы Нигезләмә таләпләренә туры килә торган конкурс проектлары Конкурста катнашуга кертелә. Конкурска Татарстан Республикасының билгеле бер туристлык юнәлешенә, туристлык үзәгенә, туристлык индустриясе объектына яисә тулаем туристлык комплексына бәйле булган, республиканың туристлык продуктын булдыруга, үстерүгә яисә камилләштерүгә, Татарстан Республикасына Россиянең һәм чит илләрнең туристларын җәлеп итүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәрне үз эченә алган конкурс проектлары тапшырыла.

3.4. Конкурс дүрт яшь төркемендә үткәрелә:

1) Башлангыч гомуми белем бирүче гомумбелем оешмаларыннан катнашучыларның конкурс проектлары (1-4 сыйныф укучылары, 7-10 яшьлекләр).

2) Төп гомуми белем бирүче гомумбелем оешмаларыннан катнашучыларның конкурс проектлары (5-9 сыйныф укучылары, 10-15 яшьлекләр).

3) Урта (тулы) гомуми белем бирүче гомумбелем оешмаларыннан (10-11 сыйныф укучылары) һәм һөнәри белем бирү оешмаларыннан катнашучыларның (15-18 яшьлекләр) конкурс проектлары.

4) Югары белем бирү оешмаларында катнашучыларның һәм эшләүче яшьләрнең конкурс проектлары (19-25 яшьлекләр).

3.5. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә, аларның һәркайсы әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән яшь төркемнәренең берсенә туры килә:

1) «Татарстан Республикасында кая барырга теләр идем» темасына иң яхшы рәсем.

Бу номинациядә әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән беренче яшь төркеменең конкурс проектлары катнаша.

Әлеге номинациядә 5 кешегә кадәр төркем тарафыннан башкарылган күмәк эшләр генә катнаша ала. Бер сыйныфтан өчтән дә артык булмаган күмәк эш кабул ителә.

Бу номинациянең конкурс проекты Татарстан Республикасының үзенчәлекле туристлык урыннарына багышланган рәсем һәм эсседән тора.

Эссе ирекле прозаик инша, фикер йөртүдән гыйбарәт, бу темага шәхси тәэсирләр һәм фикерләр (10 алып 20 кадәр җөмлә) белдерә.

2) Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты.

Бу номинациядә әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән икенче яшь төркеменең конкурс проектлары катнаша.

Әлеге номинациядә 5 кешегә кадәр төркем тарафыннан башкарылган күмәк эшләр генә катнаша ала.

3) Туризм төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты, түбәндәге бүлекләр буенча:

авылча туристлык маршруты;

этнотуризм маршруты;

актив туристлык һәм ял маршруты;

гастрономик туристлык маршруты.

Бу номинациядә әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән өченче яшь төркеменең конкурс проектлары катнаша.

Әлеге номинациядә индивидуаль яисә 5 кешегә кадәр төркем тарафыннан башкарылган күмәк эшләр катнаша ала.

«Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты», «Туризм төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты» номинацияләрендә тәкъдим ителгән конкурс проекты

экскурсия маршрутын, маршрут картасын, экскурсиянең контроль текстын һәм экскурсовод портфелен үз эченә ала.

Экскурсиянең маршруты экскурсия төркеменә хәрәкәт итү өчен иң уңайлы юлдан гыйбарәт. Маршрут әлеге экскурсия өчен объектларны карауның, төркемне урнаштыру өчен мәйданчыклар булуның иң дөрес эзлеклелегенә карап төзелә. Маршрут бурычларының берсе – экскурсия темасын булдыра алганча тулы итеп ачарга ярдәм итү. Маршрут төзелешенә карата төп таләпләр – ул объектларны мантыйкый эзлеклелектә күрсәтүне оештыру һәм теманы ачу өчен күзәтү нигезен тәэмин итү.

Экскурсиянең контроль тексты – экскурсантларга җиткерелә торган мәгълүматларның фәнни, актуальләштерелгән эчтәлеген үз эченә ала торган технологик документ. Контроль текст нигезендә экскурсияче экскурсиячечень үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен чагылдыра торган һәм билгеле бер экскурсантларның мәнфәгатьләренә җавап бирә торган аерым текст төзи (чыганак: ГОСТ Р 54604-2011. Россия Федерациясенең Илкүләм стандарты. Туристлык хезмәтләре. Экскурсия хезмәтләре. Гомуми таләпләр).

«Экскурсиясе портфеле» – экскурсияче тарафыннан экскурсияне үткәрү барышында кулланыла торган мәгълүмати материаллар комплектының (фотолар, документларның күчермәләре, география карталары, схемалар, картина репродукцияләре һ.б.) шартлыча аталышы (чыганак: ГОСТ Р 54604-2011. Россия Федерациясенең Илкүләм стандарты. Туристлык хезмәтләре. Экскурсия хезмәтләре. Гомуми таләпләр).

4) Татарстан Республикасы буенча иң яхшы виртуаль экскурсия.

Бу номинациядә катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктының 3, 4 пунктчаларында күрсәтелгән өченче һәм дүртенче яшь төркемнәренең конкурс проектлары кабул ителә.

Әлеге номинациядә индивидуаль яисә 5 кешегә кадәр төркем тарафыннан башкарылган күмәк эшләр катнаша ала.

Виртуаль экскурсия Power Point, pdf презентациясе рәвешендә 3D панорамаларына нигезләнгән 360 яки 3D визуализациягә нигезләнгән интерактив виртуаль проект. Минималь рөхсәт – 4:3 өчен 480x272, 16:9 өчен 480x272, ориентация – горизонталь.

5) Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект.

Бу номинациядә әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән дүртенче яшь төркеменең конкурс проектлары катнаша.

Әлеге номинациядә индивидуаль башкарылган конкурс проектлары катнаша ала.

«Туризм өлкәсендә иң яхшы проект» номинациясендә Татарстан Республикасына туристларны җәлеп итү белән бәйле конкурс проекты тәкъдим ителә. Конкурс проекты түбәндәге темаларның берсе буенча тапшырыла:

Татарстан Республикасы муниципаль районына туристларны җәлеп итү;

Татарстан Республикасының туристлык потенциалын алга этәрү;

Татарстан Республикасының туризм өлкәсен цифрлаштыру.

Конкурс проекты проектның төп идеясен, максатларын һәм бурычларын, максатларга ирешү стратегиясен һәм механизмнарын, чаралар планын/графигын, күздә тотылган финанс чыгымнарын, планлаштырылган нәтиҗәләрне, Татарстан Республикасы өчен үсеш перспективаларын күрсәтеп, проектка тасвирламаны үз эченә ала.

6) Иң яхшы видео-экскурсия.

Бу номинациядә әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктының 1, 2, 3 пунктчаларында күрсәтелгән беренче, икенче һәм өченче яшь төркемнәренең конкурс проектлары кабул ителә.

«Иң яхшы видео-экскурсия» номинациясендә видеороликның минималь рөхсәте – 4:3 өчен 480х360, 16:9 өчен 480х272, кимендә 240 px (пиксель), юнәлеше – горизонталь.

3.6. Конкурска түбәндәге материаллар тапшырыла:

билгеләнгән формалы анкета-гариза (әлеге Нигезләмәнең 1, 2, 3, 4, 5, 6 нчы кушымталары);

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (киңәш ителә торган формалар әлеге Нигезләмәнең 8, 9, 10, 11 нче кушымталарында китерелгән);

проект документлары, түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

басма материаллар: Word форматындагы текст (шрифтның зурлыгы – 12, юллар арасындагы интервал – берле), текстның күләме – аралыклар белән 30 000 басма билгегә кадәр;

фотография материаллары: PDF/JPG форматында (15 фотодан артык түгел);

флеш-чыганакларда аудио- һәм видеоматериаллар;

видеороликның минималь рөхсәте – 4:3 өчен 480х360, 16:9 өчен 480х272, кимендә 240 px (пиксель), юнәлеше – горизонталь;

теләсә кайсы техникада А4/А3 форматындагы кәгазьдә төсле башкарылган рәсем (төсле карандашлар, буяулар, балавыз акбурлары). Рәсем Конкурсның оештыру комитетына ике төрдә тапшырыла: оригинал әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән почта адресына бирелә; рәсемнең фотосы (мөмкинлеге кимендә 1920х1080) һәм сканер аша уздырылган хезмәт әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән электрон адреска җибәрелә;

эссе кереш, төп өлеш, бәяләмә өлешеннән тора. Эссенең күләме А4 форматындагы ике биттән артмаска тиеш (10 алып 20 кадәр җөмлә).

Барлык конкурс материаллары кәгазьдә, флеш-чыганакта һәм электрон рәвештә (конкурсның электрон почтасы) тапшырыла.

Тапшырылган барлык документларның текстлары авторның исем-фамилиясен һәм белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманың атамасын күрсәтүдән башланырга тиеш.

Теләсә кайсы чит телдәге Конкурс материаллары рус теленә тәрҗемәсе булган очракта гына тапшырыла.

3.7. Шушы Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән датадан соң тапшырылган конкурс материаллары каралмый һәм Конкурста катнашуга кертелми.

3.8. Гариза бирү датасы булып аның конкурсның электрон почтасына керү датасы санала.

3.9. Әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында күрсәтелгән кирәкле документлар булмаганда, эш каралмый. Мөрәҗәгать итүчегә конкурс эшен конкурста катнашуга гаризада күрсәтелгән электрон почтага җибәрүдән баш тарту турында мондый карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә хәбәр ителә. Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән срокта җитешсезлекләрне бетергәннән соң, кабат гариза бирә ала.

3.10. Конкурста катнашуга кертелмәгән гариза бирүчеләр, гаризалар бирү өчен билгеләнгән срокта җитешсезлекләрне бетергәннән соң, кабат конкурска гариза бирә ала.

3.11. Конкурска тәкъдим ителгән барлык материаллар кире кайтарылмый һәм рецензияләнми.

## 4. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

4.1. Килгән конкурс проектларын бәяләү максатында Дәүләт комитеты тарафыннан Конкурс комиссиясе (алга таба –Комиссия) төзелә.

4.2. Комиссиянең персональ составы 12 кеше күләмендә Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

4.3. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, җаваплы сәркатипдән, республика башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасының туристлык һәм иҗтимагый оешмалары, фәнни җәмәгатьчелек вәкилләреннән тора.

4.3. Комиссия рәисе Комиссия утырышын җитәкли һәм үткәрә.

4.4. Комиссия рәисе булмаганда, бурычлар аның урынбасарына (алга таба – рәислек итүче зат) йөкләнә. Конкурс нәтиҗәләре турында шәхсән кызыксынган затлар Комиссия әгъзалары була алмыйлар.

4.5. Комиссиянең эше утырышта гамәлгә ашырыла. Әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, утырыш тулы хокуклы булып санала. Комиссиянең җаваплы сәркатибе тавыш бирү хокукына ия түгел.

4.6. Комиссиянең җаваплы сәркатибе түбәндәге функцияләрне үти:

шушы Нигезләмәнең 3.6-3.10 пунктларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, материалларны кабул итә һәм терки, һәм аларның саклануын тәэмин итә;

Комиссиянең утырышын оештыра, документларны әзерли һәм беркетмә рәсмиләштерә.

4.7. Комиссия карары Комиссия утырышы уздырылган көнне беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа рәислек итүче зат, җаваплы секретарь һәм комиссия әгъзалары кул куя.

## 5. Конкурста сайлап алу тәртибе

5.1. Конкурста җиңүчеләр Комиссия утырышында билгеләнә.

5.2. Конкурсның һәр номинациясендә дүрт яшь төркеме буенча өч җиңүче – 1, 2, 3 урыннар билгеләнә. Конкурсның һәр номинациясендә җиңүчеләр Дәүләт комитетының махсус дипломнары һәм истәлекле призлары белән бүләкләнә.

5.3. Конкурсның һәр катнашучысы, аның эшен караган очракта, катнашкан өчен Диплом белән бүләкләнә.

5.4. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү 5 баллы шкала буенча (әлеге Нигезләмәнең 7 нче кушымтасында китерелгән форма буенча) катнашучыларның конкурс проектлары сыйфатын бәяләү критерийлары нигезендә башкарыла.

5.5. Һәр критерий буенча Комиссия әгъзасы 5 баллы шкала буенча бәя куя. Һәр критерий буенча билгеләрнең суммасы Конкурста катнашучыга гомуми билгене бирә.

5.6. Һәр критерий буенча бәяләр суммасы буенча Комиссия конкурста катнашучылар рейтингын төзи. Рейтинг нигезендә Комиссия конкурста җиңүчеләр исемлеген төзи.

5.7. Номинацияләрнең берсенә бер генә гариза бирелгән, бер гариза да бирелмәгән, бирелгән гаризаларның берсе генә дә Конкурс шартларына туры килми икән, номинациядә җиңүче билгеләнмәгән очракларда, Конкурс әлеге номинация буенча үткәрелми.

5.8. Конкурска бер генә гариза да бирелмәгән, җиңүче билгеләнмәгән очракта, Конкурс узмаган дип таныла.

5.9. Конкурс комиссиясе үзе Конкурс таләпләренә тулысынча җавап бирә торган Конкурс проектлары тәкъдим ителмәсә, бер яки берничә призлы урын бирмичә калдыру хокукына ия.

5.10. Тигез балл җыйган берничә катнашучы булса, җиңүче тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Комиссия тарафыннан билгеләнә. Комиссия утырышында рәислек итүче затның тавышы, тавышлар тигез булганда, хәлиткеч санала.

5.11. Конкурс йомгаклары Дәүләт комитеты боерыгы белән Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә имзаланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта рәсмиләштерелә.

5.12. Конкурс нәтиҗәләре Дәүләт комитеты тарафыннан (аерым сценарий нигезендә) 2022 елның 25 ноябреннән дә соңга калмыйча Конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыру тантанасында игълан ителә.

Конкурс нәтиҗәләре турында игълан Дәүләт комитеты сайтында Конкурста җиңүчеләргә һәм дипломантларга бүләкләр тапшыру тантанасы уздырылган көнне басыла.

5.13. Конкурсны оештыручы түбәндәгеләрне үз ихтыярында калдыра:

тапшырылган конкурс проектларын үзәк, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару хокукын;

материалларны челтәрләрле теле- һәм радиокомпанияләрнең эфирларында урнаштыру хокукын;

Конкурста җиңүчеләрнең конкурс проектларын Дәүләт комитеты сайтында катнашучы авторлыгына сылтама белән бастырып чыгарырга.

5.14. Катнашучылар Конкурска үзләренең конкурс проектларын җибәрү факты белән шушы Нигезләмәнең барлык шартлары белән дә тулысынча һәм берсүзсез риза булуларын раслыйлар.

2022 елда XIII «Чыганакларга
сәяхәт» республика конкурсын
үткәрү турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

2022 елда XIIШ «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсында катнашучы өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

«Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты» номинациясе

| |
|---|
| 1. Тутыру датасы «_____» _____________ 2022 ел.<br><br>2. Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (тулысынча)<br>____________________________________________<br><br>3. Яше ______________________________<br><br>4. Җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)<br>____________________________________________<br>____________________________________________<br><br>5. Катнашучының яшәү урыны буенча адресы / белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешма адресы:<br>____________________________________________<br>____________________________________________<br>____________________________________________<br><br>6. Элемтә өчен телефоннар, электрон почта (e-mail)______________________<br>____________________________________________<br>7. Катнашучы турында мәгълүматлар:<br>- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың атамасы /эш урыннары h. б. (тулысынча)<br>____________________________________________<br>____________________________________________<br>- өстәмә башка белешмәләр ______________________________<br>____________________________________________<br>____________________________________________<br><br>8. Эшнең исеме, кыскача аңлатма<br>____________________________________________<br>____________________________________________ |
| 9. Конкурс комиссиясе нәтиҗәләре |

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIII республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

АНКЕТА-ГАРИЗА

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIII республика конкурсында катнашучыдан
«Туризм төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты» номинациясе:
Бүлек (кирәклесен аерып күрсәтергә)

- авылча туристлык маршруты
- этнотуристлык маршруты
- актив туристлык һәм ял маршруты
- гастрономик туристлык маршруты

1. Тутыру датасы «_____» ______________ 2022 ел.
2. Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (тулысынча)
________________________________________________________________________
3. Яше ____________________________
4. Җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
________________________________________________________________________
5. Катнашучының яшәү урыны адресы:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
6. Элемтә өчен телефоннар, электрон почта (e-mail)______________________________________________________
7. Катнашучы турында мәгълүмат:
- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың атамасы /эш урыннары һ. б. (тулысынча)
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
- башка өстәмә белешмәләр ___________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
8. Хезмәтнең аталышы, кыскача аннотациясе
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
______________________

Конкурс комиссиясе йомгаклары

2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт»
республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 3 нче
кушымта

2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсында катнашучы өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

Иң яхшы видео-экскурсия номинациясе

○

1. Тутыру датасы «_____» _____________ 2022 ел.
2. Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (тулысынча)
   ______________________________________________
   ______________________________________________
3. Яше _________________________________
4. Җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
   ______________________________________________
   ______________________________________________
5. Катнашучының яшәү урыны буенча адресы / белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешма адресы: ______________________________________________
   ______________________________________________
   ______________________________________________
6. Элемтә өчен телефоннар, электрон почта (e-mail)______________________________
   ______________________________________________
7. Катнашучы турында мәгълүматлар:

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың атамасы /эш урыннары һ. б. (тулысынча)

______________________________________________

______________________________________________

- өстәмә башка белешмәләр ______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

8. Эшнең исеме, кыскача аңлатма

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

9. Конкурс комиссиясе нәтиҗәләре

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт»
XIII республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 4 нче
кушымта

АНКЕТА-ГАРИЗА

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIII республика конкурсында катнашучыдан

«Татарстан Республикасы буенча иң яхшы виртуаль экскурсия» номинациясе

| |
|---|
| 1. Тутыру датасы «_____» _____________ 2022 ел.<br><br>2. Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (тулысынча)<br>_______________________________________________<br><br>3. Яше ______________________________<br><br>4. Җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)<br>_______________________________________________<br>_______________________________________________<br><br>5. Катнашучының яшәү урыны адресы:<br>_______________________________________________<br>_______________________________________________<br><br>6. Элемтә өчен телефоннар, электрон почта (e-mail)______________________________<br>_______________________________________________<br><br>7. Катнашучы турында мәгълүмат:<br>- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың атамасы /эш урыннары һ. б. (тулысынча)<br>_______________________________________________<br>_______________________________________________<br>- башка өстәмә белешмәләр ______________________________<br>_______________________________________________<br>____<br>8. Хезмәтнең аталышы, кыскача аннотациясе<br>_______________________________________________<br>_______________________________________________<br>_______________________________________________<br>_______________________________________________<br>_______________________________________________ |
| Конкурс комиссиясе йомгаклары |

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт»
XIII республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 5 нче
кушымта

АНКЕТА-ГАРИЗА

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIII республика конкурсында катнашучыдан

«Туристлык өлкәсендә иң яхшы проект» номинациясе

| |
|---|
| 1. Тутыру датасы «_____» _____________ 2022 ел.<br><br>2. Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) (тулысынча)<br>____________________________________________________________<br><br>3. Яше ______________________________<br><br>4. Җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)<br>____________________________________________________________<br>____________________________________________________________<br><br>5. Катнашучының яшәү урыны адресы<br>____________________________________________________________<br>____________________________________________________________<br><br>6. Элемтә өчен телефоннар, электрон почта (e-mail)________________________________________________<br>____________________________________________________________<br><br>7. Катнашучы турында мәгълүмат:<br>- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың атамасы /эш урыннары һ. б. (тулысынча)<br>____________________________________________________________<br>____________________________________________________________<br>- башка өстәмә белешмәләр ______________________________________<br>____________________________________________________________<br><br>8. Хезмәтнең аталышы, кыскача аннотациясе<br>____________________________________________________________<br>____________________________________________________________<br>____________________________________________________________<br>____________________________________________________________ |
| Конкурс комиссиясе йомгаклары |

2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт»
республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 6 нче
кушымта

2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсында катнашучы өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

Номинация: «Татарстан Республикасында мин кая барырга теләр идем» темасына иң яхшы рәсем»

1. Тутыру датасы «_____» _____________ 2022 ел.
2. Белем бирү оешмасының атамасы
______________________________________________________________
______________________________________________________________
3. Белем бирү оешмасы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
______________________________________________________________
4. Белем бирү оешмасы директорының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
______________________________________________________________
5. Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманың урнашу урыны буенча адресы: ______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
6. Элемтә өчен җитәкченең телефоннары, электрон почтасы (e-mail)____________________
______________________________________________________________
7. Конкурста катнашучылар турында мәгълүмат фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), Сыйныф

1______________________________________________________________
2______________________________________________________________
3______________________________________________________________
4______________________________________________________________
5______________________________________________________________

8. Эшнең исеме, кыскача аңлатма (эссе)
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________

9. Конкурс комиссиясе нәтиҗәләре

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт»
XIII республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 7 нче
кушымта

Катнашучыларның конкурс проектларының сыйфатын бәяләү критерийлары

| Критерийның аталышы | Баллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Конкурста игълан ителгән тематикага туры килүе | | | | | |
| Эшнең сыйфаты (теманы тулысынча ачуы, идеясенең оригинальлеге, аның яңалыгы, мәгълүматлылыгы, грамматик һәм лексик дөреслеге) | | | | | |
| Туристлык төшенчәләрен һәм терминнарын белүе, аларны куллану дөреслеге | | | | | |
| * “Экскурсия уздыручы портфеле” (фотолар, документларның күчермәләре, географик карталар, схемалар, картиналардан репродукцияләр) | | | | | |
| *Экскурсиянең контроль тексты (экскурсантларга җиткерелә торган мәгълүматның фәнни, актуальләштерелгән эчтәлеген үз эченә алган технологик документ) | | | | | |
| * Маршрутның карта-схемасы (маршрут төзелешенең мантыйкый иң уңайлы юлы, объектларны карау эзлеклелеге) | | | | | |
| **Проектны җентекле нигезләү (проектның төп идеясен, максатларын һәм бурычларын, максатларга ирешү стратегиясен һәм механизмнарын, чаралар планын/графигын, күздә тотылган финанс чыгымнарын, планлаштырылган нәтиҗәләрне, Татарстан Республикасы өчен үсеш перспективаларын күрсәтеп, проектка тасвирлама) | | | | | |
| *** Техник гамәлгә ашырылуы (видеога төшерү сыйфаты (видеороликның минималь рөхсәте – 4:3 өчен 480х360, 16:9 өчен 480х272, кимендә 240 px (пиксель), юнәлеше – горизонталь), үзара бәйләнеш һәм масштаб линияләрен, композицияләрне үтәү, планнар, яктылык һәм төсләр бәйләнеше, видеоролик планының материалны бербөтен буларак кабул итү мөмкинлеген бирә торган мантыйкый эчтәлеге) | | | | | |
| **** Рәсемне сәнгатьчә башкару (эш эчтәлегенең күрсәтелгән тематикага туры килүе,<br>сәнгать осталыгы (эшне башкару техникасы һәм сыйфаты), иҗади дәрәҗәнең авторның яшенә туры килүе, фикеренең оригинальлеге) | | | | | |
| **** Эссе темасын ачу, эчтәлекле итү, эчтәлекнең темага һәм рәсемгә туры килүе, эзлеклелек һәм мантыйклык, сәяхәт өчен сайланган урынның нигезләнүе, эссенең күләме (10-20 җөмлә) | | | | | |
| ***** Виртуаль экскурсиянең эчтәлеге, тәкъдим ителгән объектларның саны, сурәтләрнең сыйфаты, текст мәгълүматының оптимальлеге, текстта (грамматик, пунктуацион, стилистик) хаталар булмау. | | | | | |
| ***** Power Point, pdf презентация 3D панорамалар 360 яки 3D визуализация нигезендә булдырылган, катнашкан кебек чагылыш бирә торган.<br>Минималь рөхсәт – 4:3 өчен 480х272, 16:9 өчен 480х272, ориентация – горизонталь. | | | | | |

* «Иң яхшы мәдәни-танып-белү маршруты», «Туризм төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты» номинацияләрендә бәяләнә

** «Туризм өлкәсендә иң яхшы проект» номинациясендә бәяләнә

*** «Иң яхшы видео-экскурсия» номинациясендә бәяләнә

**** «Татарстан Республикасында мин кая барырга теләр идем» темасына иң яхшы рәсем» номинациясендә бәяләнә

***** «Татарстан Республикасы буенча иң яхшы виртуаль экскурсия» номинациясендә бәяләнә

2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 8 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә

ризалык

Мин, ______________________________________________________________________________,
(Фамилия, исем, ата исем (соңгысы – булган очракта))

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына, 2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсында катнашу максатларында, шулай ук «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына күрсәтелгән чарада катнашу өчен үзем тапшырган белешмәләрне автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан башка гына да, эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге ризалык бу белешмәләрне үз эченә алган тиешле мәгълүматларны яки документларны саклау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чор беткәнчегә кадәр бирелә.

__________________ ______________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

дата

2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт»
республика конкурсын үткәрү турындагы
нигезләмәгә 9 нчы кушымта

Киңәш ителә торган форма

14 яше тулмаган балигъ булмаган бала исеменнән шәхси мәгълүматларны
эшкәртүгә ризалык турында гариза

Мин, ______________________________________________________________,
(Фамилия, исем, ата исем (соңгысы – булган очракта))
___________________________________________________ исеменнән эш итәм,
(Мәнфәгатьләре яклана торган затның фамилиясе, исеме, атасының исем (соңгысы – булган очракта))
____________ елда туган, туу турында таныклыгы, ___________________________
(көне, ае һәм елы) (сериясе һәм номеры
___________________________________________________________________
кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
яши торган адрес: ___________________________________________________,
(мәнфәгатьләре яклана торган затның теркәлү урыны адресы)
Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына
____________________________________________________________нигезендә
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ реквизитлары)
«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә түбәндәгенең шәхси мәгълүматларын автоматлаштырылган рәвештә, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча гына да, эшкәртүгә ризалык бирәм
____________________________________________________________________
(мәнфәгатьләре яклана торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсында катнашу максатларында, әлеге чарада катнашу өчен Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына мин тапшырган мәгълүматлар белән, аерым алганда, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне кылуга ризалык бирәм.

Әлеге ризалык бу белешмәләрне үз эченә алган тиешле мәгълүматларны яки документларны саклау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чор беткәнчегә кадәр бирелә.

_________________________ ____________________________________________
(законлы вәкилнең имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

дата

20212елда XIII «Чыганакларга сәяхәт»
республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 10 нче
кушымта

Киңәш ителә торган форма

14 яше тулган балигъ булмаган бала исеменнән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык турында гариза

Мин, ________________________________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исем (соңгысы – булган очракта))
____________________________________________________________________ризалыгы белән
(законлы вәкилнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
паспорт ___________________________________________________________________
(законлы вәкил паспортының сериясе һәм номеры,
_________________________________________________________________________,
паспорт кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
яши торган адрес: ____________________________________________________________,
(законлы вәкилнең теркәлү урыны адресы)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына, 2022 елда XIII «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсында катнашу максатларында, шулай ук «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына күрсәтелгән чарада катнашу өчен үзем тапшырган белешмәләрне автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларыннан башка гына да, эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге ризалык бу белешмәләрне үз эченә алган тиешле мәгълүматларны яки документларны саклау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чор беткәнчегә кадәр бирелә.

____________________________ ____________________________________________
(законлы вәкилнең имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

дата

2022 елда «Чыганакларга сәяхәт»
XIII республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә 11 нче
кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ______________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

________________________________________________________________________________,
(почта адресы)

________________________________________________________________________________
(электрон почта адресы, телефон номеры)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына (алга таба – оператор) (ОГРН 1141690023364, ОКТМО 92701000001, ОКПО 48694992), Юридик адресы: 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Максим Горький урамы, 19 йорт, 2022 елда «Чыганакларга сәяхәт» XIII республика конкурсында катнашу максатында үземнең шәхси мәгълүматларымны таратуга (тапшыруга, бирүгә) ризалык бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм исемлеге

| Т/с | Шәхси мәгълүматлар | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | ӘЙЕ | ЮК |
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | | | |
| 1. | Фамилия | | |
| 2. | Исем | | |
| 3. | Ата исеме (булган очракта) | | |
| 4. | Туган ел, ай, дата һәм туу урыны | | |
| 5. | Адрес | | |
| 6. | Уку урыны | | |
| 7. | Эш урыны/вазыйфа | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган шәхси мәгълүматларның категорияләре һәм исемлеге

| Т/с | Шәхси мәгълүматлар | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. | [Шәхси мәгълүмат категорияләре] | |
| | [Шәхси мәгълүматлар исемлеге] | |

Искәрмә. Әлеге юл шәхси мәгълүматлар субъектының ихтыяры буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүче оператор ягыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар затларның чикләнмәгән яки чикләнгән даирәсенә шәхси мәгълүматларны тарату һәм (яки) бирү буенча оператор башкара торган гамәлләрне чикләү яки тыюны күздә тота.

Ризалыкта өстәмә рәвештә шәхси мәгълүматларны эшкәртә торган оператор тарафыннан алынган шәхси мәгълүматларның бары тик анық катгый билгеләнгән хезмәткәрләр өчен генә мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге тәэмин ителгән эчке челтәре аша гына яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырыла алуы яки алынган шәхси мәгълүматларның тапшырылмау шартлары күрсәтелә ала.

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматлары оператор тарафыннан затларның чикләнмәгән даирәсенә тапшырылачак һәм алар белән башка төрле гамәлләр кылыначак мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: https://tourism.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ____________________________________________________________гамәлдә була.
(ризалыкның конкрет гамәлдә булу вакытын күрсәтергә)

Шәхси мәгълүматлар субъекты, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, үз шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алырга хокуклы.

Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан үзе биргән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы кире алынган очракта, оператор аларны эшкәртүдән туктарга яисә мондый эшкәртүнең туктатылуын тәэмин итәргә тиеш (әгәр шәхси мәгълүматларны эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча эш итүче башка зат тарафыннан гамәлгә ашырылса) һәм, шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатында шәхси мәгълүматларны саклау таләп ителмәгән очракта, аларны кире алу турында гариза алынган датадан башлап утыз көннән артмаган чорда юкка чыгарырга яки юкка чыгарылуын тәэмин итәргә тиеш (әгәр шәхси мәгълүматларны эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча эш итүче башка зат тарафыннан гамәлгә ашырылса). Күрсәтелгән чорда шәхси мәгълүматларны юкка чыгару мөмкинлеге булмаса, оператор мондый шәхси белешмәләрне блокка куя яки блокка куелуын тәэмин итә (әгәр шәхси мәгълүматларны эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча эш итүче башка зат тарафыннан гамәлгә ашырылса) һәм алты айдан артмаган чорда шәхси мәгълүматларның юкка чыгарылуын тәэмин итә.

__________________ ____________________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

дата